Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районының
Кече Талкыш авыл җирлеге Советы

**КАРАРЫ**

2020 елның 18 июне № 80/1

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Кече Талкыш авыл җирлеге Советының
дүртенче чакырылыш депутатларын
сайлаулар билгеләве турында

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” гы 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясы, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 2007 елның 7 маендагы 21-ТРЗ номерлы 105 статьясындагы 1 өлеше, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Кече Талкыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Кече Талкыш авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Кече Талкыш авыл җирлеге Советының дүртенче чакырылыш депутатларын сайлауларны 2020 елның 13 сентябренә билгеләргә.
2. Әлеге карарны «Чистай хәбәрләре» газетасында кабул ителгәннән соң биш көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарырга, авыл җирлегендә яшәүчеләрне күпләп җыелган урыннарда, игълан такталарында һәм стендларында урнаштырырга һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтының «Кече Талкыш авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.

Кече Талкыш
авыл җирлеге башлыгы Г.Н. Федотов